**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Яңа Усы авыл җирлегенә керүче Бикмәч авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№1** **05.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Яңа Усы авыл җирлегенә керүче
Бикмәч авылында узган
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 нчы елның 05 нче декабрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы Яна Усы авыл җирлегенә караган Бикмәч авылында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча Карарны кабул ителгән дип танырга («РИЗА» - 26, «КАРШЫ» - 0): «Сез, 2020 елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:
- Бикмәч авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- Бикмәч авылы мәдәният оешмаларының ялын оештыру һәм анда яшәүчеләрне хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Бикмәч авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру;
- Бикмәч авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;
- Бикмәч авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Бикмәч авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Бикмәч авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Мөслим муниципаль районы, Яңа Усы авылы, Совет урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы** **Г.С. Романова**